**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2024елның 09 феврале 200 номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Нармонка авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:24:000000:2043 кадастр номерлы җир участогы территориясен планлаштыру һәм чикләү проектын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 14.08.2023 елның 14 августындагы 2578 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42,45,46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир участоклары чикләрен, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир участоклары чикләрен билгеләү максатларында, 2024 елның 26 гыйнварында уздырылган гавами тыңлаулар нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Нармон авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:24:000000:2043 кадастр номерлы җир кишәрлеген планлаштыру һәм чикләү проектына, кызыл линияләр үзгәрү өлешендә, үзгәрешләр кертүне расларга.
2. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**